КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2023 ел, 16 май | г.Казань | № 601

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә укытуга грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 14 август, 598 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә укытуга грантлар бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 14 август, 598 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 1 сентябрь, 607 нче; 2017 ел, 26 июль, 516 нчы; 2019 ел, 2 сентябрь, 770 нче; 2020 ел, 28 август, 752 нче; 2021 ел, 15 июнь, 458 нче; 2022 ел, 7 июнь, 532 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2014 – 2023 елларга «Ачык Татарстан» Татарстан Республикасында мәгълүмат һәм коммуникация технологияләрен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 17 декабрь, 1000 нче» сүзләрен «Цифрлы Татарстан» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2021 ел, 18 октябрь, 980 нче» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Мәгълүмат технологияләре өлкәсендә укытуга грантлар бирү тәртибендә:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Цифрлы Татарстан» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2021 ел, 18 октябрь, 980 нче карары белән расланган «Цифрлы Татарстан» Татарстан Республикасы дәүләт программасының «Татарстан Республикасында мәгълүмат технологияләре өлкәсендә икътисадый мохит һәм кеше капиталын үстерүгә дәүләт ярдәме» ярдәмче программасы (алга таба – Ярдәмче программа) нигезендә эшләнде.»;

3.4 пунктта:

өченче абзацта «грант бирү турында шартнамә төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1енче көненә» сүзләрен «конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу

өчен документлар тапшырылган көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «грант бирү турында шартнамә төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1енче көненә» сүзләрен «конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен документлар тапшырылган көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага» сүзләренә алмаштырырга;

3.4.1 пунктта:

дүртенче абзацта «килешү төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1енче көненә» сүзләрен «конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен документлар тапшырылган көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага карата» сүзләренә алмаштырырга;

бишенче абзацта «грант бирү турында шартнамә төзергә планлаштырыла торган айга кадәрге айның 1енче көненә» сүзләрен «конкурс нигезендә сайлап алуда катнашу өчен документлар тапшырылган көнгә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага» сүзләренә алмаштырырга;

5.2 пунктта татар текстында «үзләштерү» сүзе алдына «100 процент» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин